РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июня 2024г. г. Альметьевск № 301

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 16.02.2024 ел, № 02-08-01/38 протестын исәпкә алып

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 16 декабрендәге 112 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 154 номерлы, 2023 елның 6 июлендәге 230 номерлы, 2023 елның 2 ноябрендәге 260 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары, контроль тикшеренүләр уздыру өчен нигез буларак файдаланыла торган муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда чаралар

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күпфатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырыла.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә түләү документларында коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен арттыру турында күпфатирлы йорт биналары милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм карап тотканда кулланыла торган белешмәләрне күрсәтү, алдагы хисап чоры белән чагыштырганда 50 % тан артыкка.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының икътисади үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов